# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге составына керүче Сахар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

11 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 11 ноябрендә «2020 елда Сахар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә :

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Суходол инеше аша җәяүлеләр күперенә таба сазлыклы урын буенча юлны төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 336 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 176 кеше . Халыкның җыела торган сумманы 300 сумнан ,500 сумга кадәр күтәрү турындагы фикерен исәпкә алып,«контейнерлар өчен мәйданчыклар төзү» мәсьәләсен «зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту» мәсьәләсенә алмаштырып, шулай ук урамнардагы үләнне чабу һәм Суходол инеше аша җәяүлеләр күперенә таба сазлыклы урын буенча юлны төзекләндерү мәсьәләләрен өстәп, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча ,җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде::
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 176 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге составына керүче Сахар авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.
2. “2020 елда Сахар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- Суходол инеше аша җәяүлеләр күперенә таба сазлыклы урын буенча юлны төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК
тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә.Адресы: Татарстан Республикасы.Алексеевск районы,Сахар авылы,Тынычлык урамы , 100 йорт; Татарстан Республикасы.Алексеевск районы,Сахар авылы,Дуслык урамы , 18 йорт;

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сахар авыл җирлеге башлыгы Л.В.Шаброва